**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «25» августыннан № 183

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 14 октябрендәге 226 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында 2025 елның 14 октябрендәге 226 нчы номерлы карары белән расланган «2026 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүленеше белән финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә 2026 ел өчен җирле бюджет цифрларын «758,351» дән «827,186» га алыштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүленеше белән финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге эчтәлектәге сүзләр белән тулыландырырга:

«Республика бюджеты: 2026 ел - 6 883,50 мең сум («Ялкын» ябык Футбол манежын җиһазлау);

Программаның «VI. Программа чаралары исемлеге» бүлегендә, «I. Җирле бюджет акчалары» өлешендә түбәндәге эчтәлекле 18 нче юл өстәргә:

«

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Спорт белән шөгыльләнү һәм югары нәтиҗәләргә | Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең барлык категорияләре өчен физик | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | 2026 - 2030 еллар | - | 68,835 | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

».

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ирешү өчен шартлар тудыру | культура һәм спорт өлкәсеннән файдалана алырлык инфраструктураны үстерү | муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Ялкын» ябык футбол манежын җиһазлау һәм карап тоту | | | | | | | | | | | | | |

«VI. Программа чаралары исемлеге» бүлегенә, «II. Республика бюджеты акчалары» өлешенә Программага түбәндәге эчтәлектә 23 нче юл өстәргә:

«

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Спорт белән шөгыльләнү һәм югары нәтиҗәләргә ирешү өчен шартлар тудыру | Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең барлык категорияләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсеннән файдалана алырлык инфраструктураны үстерү | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Ялкын» ябык футбол манежын җиһазлау һәм карап тоту | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | 2026 - 2030 еллар | - | 6883,50 | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 13 июлендәге 153 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 14 октябрендәге 226 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» карарын юкка чыгарырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https:///pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Бутина Анна Ивановнага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов